СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.02.2023 г. Агрыз № 26-2

2023 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы , “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, “Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында” Федераль законның 22 һәм 25 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында” 2022 елның 4 ноябрендәге 424-ФЗ номерлы федераль законнары, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 21.11.2022 елның 28-7/В16053 номерлы хаты, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Президенты Администрациясе җитәкчесенең “2023 елда Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп кую турында” 04.01.2023 елның 02-3 номерлы хатын үтәү йөзеннән, “Әгерҗе муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елда яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарында һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрелми дип билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пункты Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль берәмлекләре Башкарма комитеты җитәкчеләре вазыйфасына билгеләнгәндә кулланылмый.
3. Әлеге карарны “Татмедиа” АҖ филиалының Әгерҗе районы “Әгерҗе хәбәрләре” (“Агрызские вести”) газетасында бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе

муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 01.01.2023 елдан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Совет Рәисе урынбасары
Муниципаль район Башлыгы урынбасары И.И. Ямалиев